**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 елның «20» сентябреннән № 476

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе эшчәнлегенә керем китерә торган түләүле һәм башка төр керем китерә торган хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 04 декабрендәге 625 номерлы карарына үзгәреш кертү турында»

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2017 елның 17 февралендәге 181 номерлы карары һәм «2016 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр күләме турында» 2015 елның 23 сентябрендәге 698 номерлы карары нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе эшчәнлегенә керем китерә торган түләүле һәм башка төр керем китерә торган хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 4 декабрендәге 625 а номерлы карарын түбәндәге эчтәлектәге пункт белән тулыландырырга:

- «7. «Түләүле хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәне раслау хакында» һәм «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе эшчәнлегенең керем китерә торган башка социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә

куллану юлы белән һәм социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы операторы билгеләгән форматлар нигезендә алынырга мөмкин.

2. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**